ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 5-49/тэ

«Түбән Кама ЖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылысаклагычка Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 20.11.2015 № 5-28/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм, 2018 елга җайга салынулы оешманың план буенча кирәкле тулай табышын тәгаенләп, 2018 елга «Түбән Кама ЖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының "Түбән Кама ЖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылысаклагычка тарифлар билгеләү турында" 20.11.2015 № 5-28/тэ карарының (Татарстан Республикасы

Тарифлар буенча дәүләт комитетының 16.12.2016 № 5-60/тэ карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтасына, шушы карар кушымтасына туры китерелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 01.12.2017 № 5-49/тэ
карарына кушымта
«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 20.11.2015 № 5-28/тэ
карарына 1 нче кушымта

“Түбән Кама ҖЭҮ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылысаклагычка 2016-2018 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Җайга салынулы оешманың аталышы | тариф төре | Ел | Җылысаклагыч төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | Җылысакланыч җитештерелә торган җылылык энергиясе чыганагына (чыганакларына) хуҗа булган җылы белән тәэмин итүче оешма тарафыннан бирелүче җылысаклагычка тариф | | | | |
| 1.1 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | Бер ставкалы тариф, сум/куб.м | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 24,85 | 43,00 |
| | | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 26,75 | 51,94 |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 26,75 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 28,08 | - |
| 2 | Кулланучыларга җиткерелә торган җылысаклагычка тариф | | | | |
| 2.1 | «Түбән Кама ҖЭҮ» ҖЧҖ | Бер ставкалы тариф, сум/куб.м | 01.01.2016 башлап 30.06.2016 кадәр | 24,85 | 43,00 |
| | | | 01.07.2016 башлап 31.12.2016 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 25,85 | 45,07 |
| | | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 26,75 | 51,94 |
| | | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 26,75 | - |
| | | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 28,08 | -» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге